**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«24» сентябрь, 2019 ел Бәтке авылы № 8/6

Бәтке авыл җирлегендә җирле референдум
үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 23 сентябрендәге 14 номерлы карары, Бәтке авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 8/6 номерлы карары, Бәтке авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 24 ноябренә якшәмбе көнгә Бәтке авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты белән берлектә Бәтке авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны чыгарырга, җирле референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырырга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында балалар мәйданчыкларын ремонтлау һәм урнаштыру;
- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында яшел утыртмалар утырту һәм кисү;
- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында машина кую урыннары, тротуарлар төзү;
- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында юлларны төзекләндерү;
- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында кар чистарту;

- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;

- Бәтке авылында видеокүзәтү системасын урнаштыру;

- Бәтке авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларда үлән чабу;

- Бәтке, Круглое Поле авылларында, Кама, Нефтебаза поселокларында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системасын ремонтлау;

- Бәтке авылында урнашкан янгын депосын һәм янгын сүндерү машинасын карап тоту;

- коймалар сатып алу һәм Бәтке авылы Гагарин урамы буенча урнаштыру».

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Бәтке авыл җирлеге бюджеты средстволары хисабына гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.А.Ионычев